**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чираттан тыш утырыш
**КАРАРЫ**

24 ноябрь 2023 ел № 57 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы карарларының
үз көчен югалтулары хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында кодексы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 13.11.2023 ел, №16093415202300114 хокукый экспертизасы бәяләмәсе нигезендә, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. Көчен югалткан дип таныргa:

- Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) бердәнбер башкарма орган сыйфатында түләүсез катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында 2023 елның 18 сентябрендәге 45 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Ютазы районы Советының 2017 елның 21 августында кабул ителгән «Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләре тарафыннан бердәм башкарма орган буларак, яллаучы (эш бирүче) вәкиленең (сәяси партиядән тыш) бушлай нигездә коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашу яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керү өчен рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" №26 карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин